**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

__________ № ______

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Уразай башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе-балалар бакчасы» белем бирү учреждениесен үзгәртеп кору турында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 61-64 статьялары, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә, Актаныш муниципаль районының 2026 елның 26 маендагы муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиянең 32 нче бәяләмәсе нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Уразай башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе-балалар бакчасы» белем бирү учреждениесен, «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе «Уразай балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем учреждениесенә үзгәртеп корырга.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Уразай башлангыч гомуми белем мәктәбе-балалар бакчасы» үзгәртеп кору процедурасын үткәрү өчен «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры А. С. Хаҗиевны җаваплы итеп билгеләргә.

3. «Такталачык төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе директоры А.С.Хаҗиевка:

хезмәт законнарына ярашлы рәвештә, үзгәртеп корыла торган белем бирү учреждениесе штатларын кыскарту процедурасын үткәрүне тәэмин итәргә;

- «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы «Уразай башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе-балалар бакчасы» белем бирү учреждениесен законда билгеләнгән тәртиптә үзгәртеп корырга

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Такталачык төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе уставына үзгәртүләр кертү проектын әзерләргә.

4. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет»

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Ш. Бариев